РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» март 2023 ел г. Альметьевск № 656

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентны раслау турында» 2022 елның 31 мартындагы 531 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 21 ноябрендәге 465-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентны раслау турында» 2022 елның 31 мартындагы 531 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Карарга 1 нче кушымтада:

1 бүлекнең 1.2 пунктындагы ундүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- бала, шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алынган яисә опекада яисә попечительлектә торучы, тәрбиягә алган гаиләне дә кертеп йә Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда, патронат гаиләне дә кертеп, төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт яисә муниципаль белем бирү оешмасына өстенлекле кабул итү хокукына ия, анда аның абыйсы һәм (яисә) сеңлесе (тулы һәм тулы булмаган, уллыкка (кызлыкка) алынган балалар, опекуннар (попечительләр) булып шушы баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) булган балалар, ата-аналары (законлы

23 126

Зак. № 305-2000

вәкилләре) шушы баланың опекуннары (попечительләре) булган балалар, моңа «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклар керми.»;

3 бүлекнең 3.5.1.2 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«"Килешү төзү" статусы төп комплектлау чорында (01 июньнән 31 августка кадәр) бирелә, ел дәвамында әлеге статус бирелми.»;

3 бүлекнең 3.5.2.1 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Агымдагы елның төп комплектлау чорында «Шартнамә төзү» статусы, аны үзләштергәннән соң, 31 августка кадәр гамәлдә була».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов